ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
Юхмачы авыл жирлеге
Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Юхмачинского сельского
поселения
Алькеевского муниципального района

Адресы: 422885, ТР, Әлки районы,
Юхмачы авылы, Ленин урамы ,1а
Тел./факс 8(84346) 74-224

Адрес:422885, РТ, Алькеевский
район, с. Юхмачи, ул.Ленина, д.1а
тел./факс 8(84346) 74-224

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Юхмачы авылы

2025нче елның 30нчы гыйнвары 127№

2018нче елның 14нче декабрендәге
"Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәне раслаутурында"гы
Әлки муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлегенең
36нче номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

2023нче елның 12нче декабрендәге "Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында "Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 594нче Федераль законының 12нче маддәсе,2024нче елның 8нче августындагы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 232нче номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки районы Юхмачы авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.2018нче елның 14нче декабрендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында"гы 36нче номерлы (2019нчы елның 20нче мартындагы 5 нче номерлы карары, 2020нче елның 12нче февралендәге 4 нче номерлы карары, 2020нче елның 10нчы июнендәге 12нчы номерлы, 2021нче елның 30нчы июлендәге 24нче номерлы, 2023нче елның 9нчы февралендәге 68нчы номерлы карары, 2023нче елның 7нче июлендәге 75нче карары, 2024нче елның 22нче мартындагы 95 нче номерлы карары редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә
4 маддәнең 4пунктында", муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына" сүзләрен төшереп калдырырга.;

6нчы маддәнең 4нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый";

13нче маддәне яңа редакциядә үзгәртергә:

"13нче маддә.Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләртапшыру»;

13нче маддәнең 7нче пунктында "(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре)" сүзләрен төшереп калдырырга.;

13 нче маддәнең 8нче пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

13нче маддәнең 10нчы пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) " сүзләрен төшереп калдырырга.

13нче маддәнең 11нче пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

14нче маддәнең 3нче пунктындагы 5нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «5) белем һәм квалификация турында документ;»

30 нчы маддәнең 2нче пунктындагы 2.5нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.5.муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны узу чорында граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыра һәм үткәрә;»

30нчы маддәнең 2нче пунктында түбәндәге эчтәлекле2.5.1 пунктча өстәргә.:

«2.5.1.дәүләт сере булып торган белешмәләргә билгеләнгән рәвешне кертүне рәсмиләштерә;»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авылҗирлегенең мәгълүмат тактасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль район
Юхмачы авыл җирлеге
Советы Рәисе урынбасары Ф.З.Нутфуллина